| ГЛАВА МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «САРАБИКУЛОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «САРАБИККОЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШЛЫГЫ |
|---|---|
| **РЕШЕНИЕ** | **КАРАР** |

**2018 елның 27 сентябре** **№ 11**

**Сарабиккол авыл җирлеге Сарабиккол авылы территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы нигезендә,2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22,56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Сарабикколавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, «Сарабиккол авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Бу мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

«2019 елда Сарабиккол авыл җирлеге чикләрендә урнашкан 18 яшькә җиткән һәр граждандан 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчалардан файдалану белән килешәсезме соравы буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә:

Пионерская урамында вак таш җәелгән юлны ремонтлау;

Янгын сүндерү техникасын тоту өчен гаражны ремонтлау

« Әйе Юк».

2. Әлеге карарны Сарабиккол авыл җирлеге буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында бастырырга (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре»

бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Сарабиккол авыл җирлеге
муниципаль берәмлеге
башлыгы Г.Р.Гаделшина